0+

Роберт Сәлахиев

# Мин болай тырыш малай



Татарстан китап нәшрияты

УДК 821.512.145-1-93
ББК 84(2Рос=Тат)-5
С94

Рәссамы *Рөстәм Хәбибуллин*

**Сәлахиев, Р. Ф.**
С94 Мин болай тырыш малай : балалар өчен шигырьләр / Роберт Сәлахиев ; [рәссамы Рөстәм Хәбибуллин]. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2018. – 31 б. : рәс. б-н.

ISBN 978-5-298-03720-4

Авторның балалар өчен шигырьләре тупланган тәүге китабы. Әсәрләр балаларга хас йомры сүзгә, зирәклеккә, күзәтүчәнлеккә бай. Авторның җор теле, үзенчәлекле шигырьләре беркемне дә битараф калдырмас.

УДК 821.512.145-1-93
ББК 84(2Рос=Тат)-5

ISBN 978-5-298-03720-4

© Татарстан китап нәшрияты, 2018
© Сәлахиев Р. Ф., 2018



## МИН БОЛАЙ ТЫРЫШ МАЛАЙ

Каникуллар башландымы,
Мин авылга кайтамын.
Бабай сөя: «Кайтты, – диеп, –
Минем нәни шайтаным!»

Монда ямьле, монда кызык –
Зоопарктагы кебек:
Сыер, сарык, үрдәк-казлар...
Җитми монда бары эт.

Тагын бик зу-ур куян да бар,
Һәм аның балалары.
Алар төрле: соры, ала,
Агы бар, каралары.

Бик матурлар – үзләренә
Карап кына тормалы!
Арасында бар усалы –
Кулны тырный торганы.

Кайткач, куян ашатуны
Бабай миңа тапшыра.
Җәй буена туры килә
Яшел үлән ташырга.

Ашатмасаң үсмиләр шул,
Карап торырга кирәк!
Мин – бабама бер булышчы,
Мин – бабама бер terәк!

«Эшләп ашаганда гына
Тәмле була, – ди бабай, –
Булдырасың, миңа охшап,
Син бит бик тырыш малай!»

## АБЫЕМНЫҢ ЧАЛБАРЫ

Абый үсә аз-азлап,
Мин дә – аның артыннан.
Киемнәре күп кала,
Кияргә тик тартынам.

Бакчага бер барганда,
Чалбарын кигән идем,
Алдашып, яңа чалбар
Алдылар, дигән идем.

Чабып уйнап йөргәндә,
Төшеп китте чалбарым, –
Оялудан чак кына
Еламадым, чыдадым.

Кызлар авыз ердылар,
Ыштансыз малай, диеп,
Тордылар миннән көлеп,
Тутыккан калай, диеп.

Ярар, ярар, көлсеннәр,
Мин дә белермен әле, –
Берәр җае чыкканда,
Мин дә көләрмен әле!

Ярый инде, белсеннәр,
Әйтеп бирдем чынбарын:
«Төшсә төшәр, – дидем мин, –
Ул бит абый чалбары!..»



# ЭЧТӘЛЕК


Мин болай тырыш малай . . . . . . . . . . . . . . . 3
Абыемның чалбары . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5
Бик башлы егет булыр . . . . . . . . . . . . . . . . 6
Җәйгә җитми . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
Гөлләр шатлык китерә . . . . . . . . . . . . . . . . 8
Ничек атлап китәргә? . . . . . . . . . . . . . . . . 9
Калган ботка да тәмле . . . . . . . . . . . . . . . 10
Гаеп минем үземдә . . . . . . . . . . . . . . . . 11
Ураза тоттым әле . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
Асилә гөл ярата . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Солдат буласым килә . . . . . . . . . . . . . . . 14
Мин язган булсам әле... . . . . . . . . . . . . . 15
Гөмбәгә барган идек... . . . . . . . . . . . . . . 16
Мин курыкмыйм, мин батыр . . . . . . . . . . . . 17
Үпкәләү һич килешми . . . . . . . . . . . . . . . 18
Маймыл рәхмәте . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
Кышкы буран . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
Эшчән бал кортлары . . . . . . . . . . . . . . . 21
Урманга барган идек . . . . . . . . . . . . . . . 22
Колакны кисеп булмый . . . . . . . . . . . . . . 23
Чыпчыклар-чыркылдыклар . . . . . . . . . . . . . 24
Ярый әле әби бар . . . . . . . . . . . . . . . . 25
Бәрәңге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26
Тырыш кыз ул Сөмбелә . . . . . . . . . . . . . . 27
Салават күпере . . . . . . . . . . . . . . . . . 28
Бабай белән уйнадык . . . . . . . . . . . . . . . 29
Хәтере беткән, ахры . . . . . . . . . . . . . . . 30